# Авылда укыту-тәрбия эшенең башлануы һәм үсеше.



Кадыбаш авылында күп еллар яшәгән өлкән яшьтәге абый, апалар сөйләве буенча элек - электән авыл уртасында зур булмаган бер иске генә мәчет булган. Ул мәчеткә бик аз кешеләр генә урнаша алган.

1904 елда Касай авылы бае Башаров Сәгыйрь Хаҗи җитәкчелегендә земская управа суммасына Кадыбаш авылына зур яңа мәчет бинасын (хәзерге авыл клубы) сала башлап, 1905 елда төзеп бетергәннәр. Бу мәчет урынында булган иске бинаның бер өлешен Атнагол авылына мәчет итеп, бер өлешен мәчеттән калган материалларны кушып Кадыбаш авылына мәдрәсә салдыра. Ул хәзерге уку йорты артында була.

Бу мәчет һәм мәдрәсәләр барсы да авыл крестьяннары көче белән бушка эшләнелә. 1905-06 елларда мәдрәсәдә аерым хәлфәләр, муллалар, мәзиннәр ир балаларны укыта башлыйлар.

1910 елда Кадыбашка Исәнбайдан Фәхрисламов Мулланур, 1907 елда Якупов Мулланурлар килеп хәлфәлек хезмәтен үтиләр. Ә кыз балалар авыл остабикәләренә укырга йөриләр. Касай авылындагы Сәгыйрь Хаҗи мәдрәсәсенә авылдагы югары тормышлы авыл крестьян кызлары йөреп укыйлар.

1916 елда бу мәдрәсәдә аерым фәннәр - хисап, һәндәсә (геометрия), география, төрле хезмәткә өйрәнү кебек фәннәр кертелә башлый. Шулай ук зур яңалык булып рус теле кертелә . Ләкин кайбер аңсыз авыл кешеләре йогынтысында Кадыбаш кызлары - Сибәтова Наһар, Сибәтова Нурдидә, Хисматова Мәфтүхә һәм башка кызлар да укудан туктыйлар.

1901-02 елларда Кадыбаш авыл бае Халиков Нәфикъ җитәкчелегендә,аның үз өенә теркәп ,ике катлы земство мәктәбе салына. (Ул хәзерге Шакиров Галимҗан урынында була). Аны салу өчен чималны Сарапул земство идарәсе биргән була.

Бу мәктәпкә авылдан 15-20 ләп укучы йөри. Күрше авыллардан ир балалар гына укый. Соңга таба 1908-10 елларда кыз балалар да чакырыла һәм укый башлый.

Бу мәктәпкә беренче укытучы булып 1905-06 елларда Казаннан Казаков Исхак дигән мөгаллим килә. Ул рус телендә бик грамоталы була, балаларга рус теле, хисап (арифметика), һәндәсә һәм башка фәннәрне дә яхшы өйрәтә. Авылдагы кайбер картлар балаларын рус теле укытуга каршы чыгалар:”Балаларыбызны рус итәр”-диеп, Казаковның укытуына риза булмыйлар. Шуннан соң 3 ел укыткач, Казаков кире Казанга кайтып китә.

Земство мәктәбендә яңача(җәдитчә) укыту белән бергә дини укыту да кертелә.Айдаров Галиулла тарафыннан дини дәресләр бирелә.

1908 елларда Мордыбай авылыннан Котлыәхмәт, аннан соң Бакиев Заһретдин, Тирсәдән Баһавый дигән укытучылар килеп яңача укыта башлыйлар.

Авылда земство мәктәбен (4-еллык) беренче булып тәмамлаучылар земство управлениесеннән Исәнбай авылына килгән махсус комиссиягә барып экзамен бирәләр.